РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«20» апрель 2022г. г. Альметьевск №69

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы « Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында Нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать хакимиятен оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 31 маендагы 120 номерлы « Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты турында Нигезләмә хакында»гы карарына (Әлмәт шәһәр Советының 2019 елның 16 декабрендәге 182, 2021 елның 11 мартындагы 26, 2021 елның 17 июлендәге 36 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтаның 2 бүлегендә «шәһәр Башкарма комитеты вәкаләтләре:

1.1.1. 2.2 пунктның 3 пунктчасындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- шәһәр ихтыяҗлары өчен, федераль закон нигезендә, ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итә»;

1.1.2. 2.2 пунктының 4 пунктчасы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль һәм хосусый торак фондының торак урыннарын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортларны, барлык торак урыннары Россия Федерациясе милкендә яисә Россия Федерациясе субъектында булган күпфатирлы йортлардан тыш, авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле торак урыннарын күчерү турында билгеләнгән тәртиптә карар кабул итә».

Зак. № 1352-200

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлмәт шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Шәйхетдинова Ф.А.) йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»